**СОВЕТ
АЛЕКСАНДРОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**422613 н.п. им. «25 Октября»
тел: 8-(84378) -3-54-22
факс: 8-(84378) -3-54-22**

**ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛЕКСАНДР АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

**422613 н.п. им. «25 Октября»
тел: 8-(84378) -3-54-22
факс: 8-(84378) -3-54-22**

**№ 40** **2019 елның 11 октябреннән**

# Р Е Ш Е Н И Е
# КАРАР

**Җирле салымнар буенча бурычларны, пенялар һәм штрафларны түләттерүдә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Александр авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Физик затлар мөлкәтенә салым һәм җир салымы буенча недоимканы түләттерүгә, бу очракларда пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү:

- Россия Федерациясе Граждан-процессуаль законнары белән билгеләнгән тәртиптә физик затның үлеменә яисә аның вафатына игълан ителүенә;

- варисларның мирас хокукыннан баш тартуы, варислары булмаган яки мирас алмаган очракта, үлгәннәрнең яки вафат булган физик затларның пеня һәм штрафлар буенча бурычлары булу; мирас ачылганнан соң бер ел дәвамында мирас алмау.

2. Җир салымы һәм физик затлар мөлкәтенә салым буенча недоимканы түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләренең, бу салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычларның булуын раслаучы документлар булып тора: физик затның яшәү урыны буенча салым органы белешмәсе; физик затларның гражданлык хәле актларын теркәүне гамәлгә ашыручы орган физик затның үлем фактын теркәү турында мәгълүмат; мирас хокукы турында таныклык бирү турында салым органы белешмәсе.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Интернетның мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча бастырырга: htth:// pravo.tatarstan.ru, Лаеш муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: htth://laishevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Александр авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны план-бюджет комиссиясенә һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Александр авыл җирлеге Советының икътисадый үсешенә йөкләргә.

**Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы
Александр авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе
И.А.Бандурова**